РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
**СТАРОКАЗЕЕВСКОГО**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Центральная, 7, д.Караталга, 422834
тел. (8-843-77)30-4-16, факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**ИСКЕ КАЗИЛЕ**
**авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Үзәк урамы, 7 , Каратал авылы, 422834,
тел. (8-843-77)30-4-16 , факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2 март 2021 ел** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Иске Казиле авылында, 2020 елның 9 декабрендә кабул ителгән үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турында Иске Казиле авылы халык җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең 2020 елның 9 декабрендә кабул ителгән 3 номерлы, үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турындагы Иске Казиле авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 12 мартында 10 сәгать 00 минутта Иске Казиле авылы КФҮ тә үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең 2020 елның 9 декабрендәге 3 нче номерлы Иске Казиле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме:

1.) 2 пунктта “500 сум күләмендэ” сүзләрен “600 сум күләмендә” сүзләренә алмаштырырга;

2.) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 нчы пункт өстәргә:

6) торак пункт территорияләрен төзекләндерү (яңа ел чыршыларын бизәү очен уенчыклар сатып алу).

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Иске Казиле авыл җирлеге Советы карары белән расланган мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми рэвештэ хәбәр ителгән (бастырып чыгарылган) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе ________________ И.Х.Сәгдиев